Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге Советы

КАРАР

Иске Урыссу ав. № 13 13 сентябрь 2016 ел

Ютазы муниципаль районының
"Урыссу авыл җирлеге" муниципаль
берәмлеге чикләре турында

Ютазы муниципаль районы Советының Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү турындагы 2016 елның 17 июнендәге 16 санлы карары белән чыгарылган инициативасын карап, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсендәге 4 өлешенә таянып, авыл җирлеге халкының фикерен белдереп,

Урыссу авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләү белән килешергә.
2. Әлеге карарны " Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru Ютазы муниципаль районының мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Урыссу авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтҗанова Резеда Сәетнур кызына йөкләргә.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы Р.С. Мөхәмәтҗанова